МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.02.2024 Казан ш № 89

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
09.02.2024 ел, № 89 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гамәлдә булуын гражданнарның аерым категорияләренә кагылуы турында» 2023 елның 20 июнендәге 475 номерлы боерыгында:

преамбуласында «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022-2024 елларда» сүзләре белән алмаштырырга;

1.1 пунктта «2023 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә кадәр» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гражданнарның аерым категорияләренә карата гамәлдә булуы турында» 2023 елның 20 июнендәге 476 номерлы боерыгында:

преамбуласында «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022-2024 елларда» сүзләре белән алмаштырырга;

1.1 пунктта «2023 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә кадәр» сүзләре белән алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гражданнарның аерым категорияләре өчен дә гамәлдә булуы турында» 2023 елның 20 июнендәге 477 номерлы боерыгында:

преамбуласында «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022-2024 елларда» сүзләре белән алмаштырырга;

1.1 пунктта «2023 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә кадәр» сүзләре белән алмаштырырга.